БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_23_» _03_ 2020 ел № __127___

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының
балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы турында
Нигезләмәне раслау хакында

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә функцияләр башкаруны нәтиҗәле оештыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Балтач муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесенең 2020 елның 23 мартындагы
127 номерлы карарына
1 нче кушымта

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы (алга таба - ББЭ һәм ХЯ секторы) Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик зат статусыннан башка структур бүлекчәсе булып тора һәм үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе, Балтач муниципаль районы башлыгының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен җитәкләүче урынбасарына буйсына.

1.2. Сектор Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм норматив актларына, район Уставына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Секторның эшчәнлеге турыдан-туры секторның үзе тарафыннан да, шулай ук башкарма комитетның башка бүлекчәләре, дәүләт, муниципаль, иҗтимагый һәм башка оешмалар белән тыгыз хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла.

1.4. Сектор эшчәнлеге белән баш белгеч җитәкчелек итә.

1.5. Сектор хезмәткәрләренең функциональ бурычлары вазыйфаи инструкцияләр белән регламентлана.

## 2. ББЭ һәм ХЯ секторының төп бурычлары

2.1. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

2.2. Балтач муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба - ББЭ һәм ХЯК) утырышларын техник-оештыру ягыннан әзерләү.

2.3. Балтач муниципаль районында балигъ булмаганнарның тәрбиячесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча методик ярдәм күрсәтү.

2.4. Балигъ булмаганнарның тәрбиячесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендә җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын эшләүдә һәм камилләштерүдә катнашу.

2.5. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән йөкләнгән башка бурычлар.

## 3. Сектор эшчәнлегенең төп функцияләре һәм юнәлешләре

3.1. Сектор үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

3.1.1. Гражданнарга төпле (компетентлы) ярдәм күрсәтә ала торган гражданнар һәм төрле профильле махсуслаштырылган учреждениеләр арасында функциональ бәйләнешләрне билгеләү һәм үстерү.

3.1.2. Комиссия һәм ББЭ һәм ХЯ секторының эшен алып баруны да кертеп, ББЭ һәм ХЯК эшенең техник-оештыру тәэмин ителешен гамәлгә ашыру.

3.1.3. Комиссия карарлары һәм билгеләмәләре үтәлешен контрольдә тоту.

3.1.4. Кергән һәм каралган материалларның исәбен, исәпләнгән һәм бюджетка кергән штрафларны исәпкә алу.

3.2. ББЭ һәм ХЯ секторы вәкаләтләре:

3.2.1. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча кирәкле мәгълүматны билгеләүдә һәм тәэмин итүдә гражданнарга юнәлеш бирү максатында гомуми консультация үткәрү.

3.2.2. ББЭ һәм ХЯК һәм ББЭ һәм ХЯ секторының эшен алып баруны да кертеп, ББЭ һәм ХЯК эшенең техник-оештыру тәэмин ителешен гамәлгә ашыру.

1) ББЭ һәм ХЯКга карап тикшерүгә керә торган материалларны теркәү һәм өйрәнү, шул исәптән кергән материалларга юридик анализ ясау;

2) инициаторларга материалларны кире кайтару турында документларны (билгеләмәләрне) рәсмиләштерү;

3) инициаторларга эшләп бетерүгә кайтарылган административ эшләргә үзгәрешләр кертүнең дөреслеген һәм ББЭ һәм ХЯКга кире кайту вакытларын үтәүне контрольдә тоту;

4) ББЭ һәм ХЯда карала торган эшләр буенча карар проектларын, билгеләмәләрне, беркетмәләрне һәм башка документларны рәсмиләштерү;

5) Комиссия карарлары һәм билгеләмәләре үтәлешен контрольдә тоту;

6) ББЭ һәм ХЯК кабул итә торган карарларны һәм билгеләмәләрне тиешле органнарга җибәрү;

7) мәҗбүри түләттерү өчен приставларга материаллар рәсмиләштерү;

8) прокурорга, ата-аналарга, балигъ булмаган балаларга, балигъ булмаган балаларның законлы вәкилләренә һәм шәхси эшләрне караудa катнашучы башка затларга тиешенчә хәбәр итү;

9) юридик һәм физик затларга комиссия вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган хатлар, тәкъдимнәр, гарызнамәләр проектларын әзерләү;

10) административ материаллар кергән гаиләләр буенча базаны формалаштыру;

11) административ материаллар кергән балигъ булмаганнар буенча базаны формалаштыру;

12) махсус контингент базасын формалаштыру (кабат хокук бозучылар һәм күптапкыр хокук бозучылар, хөкем ителүчеләр һ. б.);

13) ББЭ һәм ХЯКга карап тикшерүгә кергән эшләр реестрын алып бару;

14) исәпләнгән һәм түләнгән штрафлар реестрын алып бару.

3.2.3. ББЭ һәм ХЯКның эш планнары һәм эше турында отчетлар проектларын әзерләү.

3.2.4. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча программалар проектларын, чаралар комплексларын, операцияләрне әзерләү.

3.2.5. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларыннан кергән мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлау.

3.2.6. ББЭ һәм ХЯК эше нәтиҗәләре буенча хисаплылыкны төзү һәм билгеләнгән вакытка тапшыру.

3.2.7. Билгеләнгән тәртиптә ББЭ һәм ХЯКга һәм ББЭ һәм ХЯК секторына бәйле документларны саклауны тәэмин итү, ББЭ һәм ХЯК утырышларының беркетмәләрен һәм карарларын вакытында һәм тулы архивлаштыру.

3.2.8. ББЭ һәм ХЯ секторында булган матди кыйммәтләрне инвентаризацияләүдә катнашу.

3.2.9. ББЭ һәм ХЯ секторының муниципаль хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү.

3.2.10. ББЭ һәм ХЯ секторы компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау органнары белән эшне оештыру.

3.2.11. Гражданнар һәм төрле профильле махсус учреждениеләр арасында гражданнарга компетентлы ярдәм күрсәтә алырлык арадашчы ролен (функциональ элемтәләрне урнаштыру һәм үстерү) гамәлгә ашыру.

3.2.2. Үз вәкаләтләре кысаларында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеген координацияләү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны гамәлгә ашыруны оештыру.

## 4. Секторның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен баш белгеч һәм әйдәп баручы белгеч йөзендә Сектор түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. дәүләт һәм муниципаль органнарыннан, башкарма комитетның структур бүлекчәләреннән һәм оешмалардан сектор компетенциясенә кергән

эшне башкару өчен кирәкле статистик, аналитик һәм башка мәгълүматларны соратырга һәм алырга.

4.1.2. сектор компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча барлык министрлыклар, ведомстволар белән үзара хат язышуны алып барырга.

4.1.3. башкарма комитетның норматив-хокукый актлары проектларын, башка документларны әзерләү һәм башка шундый чараларны гамәлгә ашыру өчен башкарма комитетның структур бүлекчәләренең һәм башка ведомстволарның хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

4.1.4. милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие, учреждение һәм оешмаларга үз вазыйфаи бурычларын үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә йөрү;

4.1.6. башкарма комитетның структур бүлекчәләре хезмәткәрләренә сектор компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча аңлатмалар, киңәшләр һәм күрсәтмәләр бирү;

4.1.7. гамәлдәге законнарга каршы килә торган документларны башкаруга һәм рәсмиләштерүгә кабул итмәү.

## 5. Секторның структурасы

5.1. Сектор структурасын түбәндәгеләр тәшкил итә:

- секторның баш белгече;
- секторның әйдәп баручы белгече.

5.2. Баш белгеч башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәсе белән вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

5.3. Баш белгеч:

5.3.1. Секторның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә.

5.3.2. Сектор хезмәткәрләре арасында вазыйфаларны бүлә.

5.3.3. Секторда законлылыкны һәм хезмәт дисциплинасын үтәүне тәэмин итә.

5.3.4. Сектор хезмәткәрләрен бүләкләү, аларга дисциплинар түләтүләр билгеләү турында тәкъдимнәр кертә.

5.3.5. Башкарма комитет җитәкчесе һәм аның урынбасарлары тарафыннан үткәрелә торган киңәшмәләрдә сектор эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнаша.

5.4. Секторның әйдәп баручы белгече башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәсе белән, секторның баш белгече белән килешенеп, вазыйфага кабул ителә һәм вазыйфадан азат ителә.

5.5. Сектор белгечләренең берсе вакытлыча булмаганда аның вазыйфаларын үтәү башка белгечкә йөкләнә.

5.6. Секторның баш белгеченең һәм әйдәп баручы белгеченең башка бурычлары вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә.

## 6. Җаваплылык

6.1. Әлеге Нигезләмә белән йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне сыйфатлы һәм вакытында үтәү өчен баш белгеч җаваплы.

6.2. Башка хезмәткәрләрнең җаваплылык дәрәҗәсе вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

## 7. Эшчәнлекне финанслау

7.1. Сектор эшчәнлеге өчен кирәкле җиһазлар, компьютер, принтер, эш телефоны, факс, канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин итү дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр исәбеннән башкарыла.

## 8. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Әлеге нигезләмә һәм аңа барлык өстәмәләр һәм үзгәрешләр башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана.

8.2. Әлеге Нигезләмәнең гамәлдә булу вакыты чикләнмәгән.